СОВЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**23 сентябрь 2025 ел** Болгар ш. **№ 1-10**

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы территориясендә реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү хокукына торглар үткәрү рәвеше турында

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы территориясендә тышкы реклама урнаштыру өлкәсендә норматив-хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы һәм "Реклама турында" 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләре урнаштыру хокукына сатулар конкурс рәвешендә үткәрелә дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетына Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы территориясендә урнаштыру рөхсәт ителә торган реклама конструкцияләренең типларын һәм төрләрен билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетына барлык милек рәвешләрендәге җир кишәрлекләрендә, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары милкендәге яисә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы муниципаль милкендәге биналарда яисә башка күчемсез мөлкәттә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасын эшләргә һәм расларга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкка җиткерергә http://pravo.tatarstan.ru һәм Спас муниципаль районының рәсми сайтында https://spasskiy.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны финанс-бюджет мәсьәләләре, икътисад һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районы
Советы башлыгы, Рәисе Р.Л. Исланов